ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08 ноябрь, 2018 ел № 27/4

Шәһәр Советының 2017 елның 15 декабрендәге «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар планы чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 21/5 санлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерециясенең Бюджет кодексы нигезендә
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2017 елның 15 декабрендәге «2018 елга, 2019 һәм 2020 еллар планы чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында» 21/5 санлы Карарына (Шәһәр Советының 2018 елның 24 гыйнварындагы 22/4, 2018 елның 21 февралендәге 23/5, 2018 елның 27 апрелендәге 24/5, 2018 елның 01 июнендәге 24/5, 2018 елның 10 августындагы 26/4 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 1 пунктның 1 пунктчасында:

– икенче абзацта «8 487 609,20» саннарын «8 557 483,13» саннарына алыштырырга;

– өченче абзацта «9 489 453,75» саннарын «9 559 155,96» саннарына алыштырырга;

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп 16.3. пунктын өстәргә:

«16.3. Татарстан Республикасы бюджетыннан кергән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 14 августындагы 2137-р санлы боерыгы нигезендә территориаль планлаштыру документларын эшләүгә каралган 23 051,99 мең сум күләмендә субсидияне шәһәр бюджетында исәпкә алырга;»;

3) түбәндәге эчтәлектәге 16.4. пунктын өстәргә:

«16.4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 01 июнендәге «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсы турында» 391 санлы карары нигезендә 2018 елда үткәрелгән республика

конкурсы җиңүчеләр һәм призерлары дип танылган территориаль иҗтимагый үзидарәләр Татарстан Республикасы бюджетыннан кергән 9 542,0 мең сум күләмендә кергән башка бюджетара трансфертларны шәһәр бюджетында исәпкә алырга»;

4) әлеге Карарның 1-5 нче кушымталары нигезендә 1 нче кушымтадагы 1 нче таблицаны, 2 нче кушымтадагы 1 нче таблицаны, 4 нче кушымтадагы 1 нче таблицаны, 6 нчы, 8 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г.Мәһдиев